УДК 821.512.145-4

*Иржан Алкая*

## СЕБЕРГӘ СӘЯХӘТ

Статья посвящена результатам научной экспедиции турецкого ученого-языковеда в Сибирь, предпринятой с целью изучения современного быта, нравов и обычаев сибирских татар. Автор, который занимается научными исследованиями в области диалектов татарского языка, в частности сибирских татар, делится своими впечатлениями от поездки.

**Ключевые слова:** тюркские языки, диалекты татарского языка, сибирские татары.

Orda bir köy var, uzakta,
O köy bizim köyümüzdür.
Gezmesek de, tozmasak da
O köy bizim köyümüzdür.

Анда бер авыл бар, еракта
Ул авыл безнең авылдыр
Гизмәсәк тә, йөрмәсәк тә
Ул авыл безнең авылдыр.

Төрки дөньяны күз алдыма китерү белән, акылыма шагыйребез Әхмәт Кудси Тәҗәрнең «Анда бер авыл бар еракта» исемле шигыре килә. Мин 1973 елда тудым, әнием җырлаган бишек җырлары, әбием сөйләгән әкиятләр белән үстем, ана телем булган төрек теле ярдәмендә дөньяны таныдым, аның ярдәме белән үз дөньямны кордым. Яшь чагымда бу телдә сөйләшкән кешеләрнең, Төркиядән тыш, башка җирләрдә дә яшәгәнлекләрен белдем. Төрки дип аталучы халыкларның иксез-чиксез киң мәйданнарны биләгәнлекләрен һәм һәр милләткә дә насыйп булмаган бай тарихка ия булганлыкларын аңлаганда, мин инде университетның тюркология бүлегендә белем алучы бер студент идем.

Элязыгда Фырат университетының Төрек теле һәм әдәбияты бүлеген 1994 елда тәмамлаганда, кардәшләремнең Балканнардан Тын океанга, Төньяк котыптан Тибетка кадәр җәелгән киң бер мәйданда яшәгәнлеген һәм татар, казакъ, кыргыз, алтай, тува, хакас, якут, башкорт һәм башка исемнәр белән телгә алынган олы Төрек ата балаларының Кытай, Монголия, Россия, Украина, Молдавия, Румыния, Югославия, Болгария, Македония, Греция, Сүрия, Гыйрак, Иран, Таҗикстан, Әфганстан, Польша, Литва кебек чит илләрдә һәм Төркия, Төньяк Кипр төрек җөмһүрияте, Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казакъстан һәм Себер кебек җирләрдә көн күргәннәрен белә идем. Шул вакыттан башлап, ул җирләргә барып, кардәшләрем белән очрашып-күрешү теләге белән яши башладым.

Беренче бөтендөнья сугышыннан соң, дөньяда көчләр балансы үзгәреп, дәүләт чикләре кабаттан билгеләнде. 1917 елдагы большевиклар революциясеннән соң, төрки дөнья белән булган бәйләнешләребез, аралашу мөмкинлекләребез бөтенләйгә юкка

чыккан иде. 1990 нчы елларга кадәр, ул җирләрдән чынбарлыкны дөрес чагылдырган мәгълүматлар килмәде, очрашулар мөмкин түгел иде. Бу да кардәшләребезгә карата булган хәсрәтебезне арттыра иде. 1990 нчы елларда, Советлар Союзы тарала башлагач, хәлләр берникадәр үзгәрде. Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Казакъстан һәм Кыргызстан бәйсез төрки җөмһүриятләр буларак, дөнья аренасында үз урыннарын алдылар. Россия эчендәге татар, башкорт, тува, хакас, алтай, чуваш, якут кебек төрле төрки халыклар да, үз автономияләре эчендә билгеле бер казанышларга ирештеләр. Тора-бара бу җирләрдә яшәүче кардәшләребез белән элемтәләр корып, алар белән аралаша башладык.

Orda bir ses var, uzakta,
O ses bizim sesimizdir.
Duymasak da, tınmasak da,
O ses bizim sesimizdir.

Анда бер аваз бар, еракта,
Ул аваз, безнең аваз.
Ишетмәсәк тә,тынмасак та,
Ул аваз безнең аваз, димәдек.

Чөнки без бер-беребезне ишетә, аңлый ала идек инде.

Университет елларындагы хыялым 1996 елда чынга ашты. Ул елларда Төрки дөньяны тикшеренүләр вакыфының җитәкчесе мәрхүм доктор, профессор Туран Язган Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Татарстан кебек өлкәләрдә төрек телендә белем бирә торган мәктәпләр ачып җибәргән иде. Туран Язган кадерле остазым филология фәннәре докторы, профессор Әхмәт Буран белән элемтәгә кереп, Татарстандагы шундый мәктәпләрдә эшләр өчен бер кеше җибәрүен сораган. Остазым, миннән: «Татарстанга барыр идеңме?», – дип сорауга, бер секунд та уйлап тормастан, «Әйе!», – дип җавап биргән идем. Шул максат белән 1996 елның ноябрь аенда Татарстанга килдем һәм Чаллы шәһәрендәге татар-төрек кызлар лицеенда бер ел төрек теле укытучысы буларак эшләдем. Яшьлек хыялларым чынга ашты, ниһаять, күп еллар буе күрешергә, дип хыялланган кардәшләрем белән очрашу бәхетенә ирештем. Бу вакыт эчендә татар телен өйрәндем, татар дөньясы һәм халкы белән якыннан таныштым. Татарстанның бик күп шәһәрләрен күрдем, моның белән генә чикләнеп калмыйча, Башкортстан республикасына, Пермь өлкәсенә барып, төрле тикшеренүләр үткәрдем. Чаллыда эшләгәндә, хәләл җефетем – Лилия белән таныштым һәм, 1998 елда өйләнешеп, үзебезнең гаилә учагын корып җибәрдек. Никахыбыздан Аллаһы Тәгалә, гаиләбезнең бизәкләре булган Алпарыслан Тукай белән Кылычарыслан Гюнай исемле ике ир бала насыйп итте. Төркиягә кайтканнан соң, төрки диалектлар, бигрәк тә татар теле белән бәйле фәнни эшчәнлегемә керештем.

Татарлар, үз башларыннан бик күп фаҗигаләрне үткәргән халык. 1552 елда Казан ханлыгы басып алынганнан соң, алар зур кыенлыклар кичергән, төрле сәбәпләр аркасында туган җирләре Идел-Урал буйларын

ташлап, бик ерак җирләргә китәргә мәҗбүр булганнар.

Бүгенге көндә татар халкының бер өлеше Себердә яши. Себер татарлары (икенче исеме – Көнбатыш Себер татарлары) бер җирдә тупланып яшәгән иң ерак татар төркемнәреннән санала. Билгеле булганча, кыпчак төркеменең әһәмиятле бер тармагын тәшкил иткән татар теле урта (казан татарлары диалекты), көнбатыш (мишәр), көнчыгыш (Көнбатыш Себер; себер татарлары) диалектларга бүленсә дә, телнең барлык өлкәләрен уртак билгеләр белән берләштергән бербөтен система буларак яши.

300 мең чамасындагы халкы булган себер татарлары хәзерге көндә Төмән, Новосибирск, Омск өлкәләрендә яшиләр. Алар үз эчләрендә Тобол-Иртыш (Төмән, Тобол, Саз төбәге, Тәбриз һәм Тара), Бараба, Том сөйләшләренә бүленәләр. Татар халкы, татар теле белән бәйле тикшеренүләрем барышында, Себер татарлары белән кызыксына башладым, аларның диалект һәм сөйләшләре турында фәнни китаплар язарга булдым. Шул сәбәпле, Казанга килеп, сүзлек, текстлар, китаплар һ.б. чыганакларны тупларга керештем. 2006 елда, Казанда алып барган тикшеренүләрем вакытында, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов белән очраштым. Мин аның белән 2000 елда Төркиянең Измир шәһәрендә үткәрелгән Халыкара симпозиумда танышкан идем. Ул миннән Казанга килүемнең максаты турында сорагач, мин себер татар диалектының грамматикасын язу өчен материал тупларга килгәнлегемне әйттем. Мондый хезмәт язачагымны ишетеп, ул бик сөенде һәм миңа кирәкле һәртөрле ярдәм күрсәтәчәген әйтте. Кулымда әзерләгән китап исемлеген карап чыгып, бер көннән соң күрешергә булдык. Иртәгесе көнне үз күзләремә үзем ышанмадым, ул мин бик күптән эзләгән китапларны алып килгән дә иде инде. Казанда булган вакыт эчендә башка чыганакларны да китерә торды. Бер вакыт аннан: «Фәрит абый, мин дә сезгә берәр нәрсә эшли алмыйммы?», – дип сорагач, ул: «Берни дә кирәкми, киресенчә, мин һәрвакыт сезгә кирәкле ярдәмне эшләргә әзер, сез бит минем халкыма, аның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә хезмәт итәргә тырышасыз. Мин синең өчен ниләр генә эшләсәм дә, аз булыр» – дип җавап бирде.

Төркиягә кайтып, себер татарларына багышланган фәнни-тикшеренү эшләремне дәвам иттем. Төмән, Омск, Новосибрск өлкәләреннән җыелган 90 текстны компьютерыма керттем, бу текстларга нигезләнеп, фонетика һәм морфология бүлекләрен яза башладым. Хезмәтнең кереш өлешендә Себер топонимының мәгънәсен, Себер татарларының тарихы һәм этник яктан килеп чыгышы, аларның башка төрки кавемнәр белән мөнәсәбәте, яшәгән җирләре, халык саны, диннәре, социаль яшәешләре, гореф-гадәтләре һәм фольклоры, Себер татар теленең төрки диалектлар эчендәге урыны, аңа багышланган хезмәтләр хакында да мәгълүмат бирдем. Хезмәт 2008 елда, Әнкарада нәшер

ителде. Ул Төркиядә һәм Казанда бик җылы кабул ителде. Фәрит абый хезмәтнең танылуына зур өлеш кертте, 2015 елның июлендә Казанда булганда, бу хезмәтне Себердә дә танытырга кирәклеген әйтте.

Себергә бару, ул мөкатдәс туфракка аяк басу, андагы кардәшләрем белән күрешү, ул җирләрнең һавасын сулау, суын эчү, икмәген ашау – минем иң зур теләкләремнең берсе иде. Ул җирләрне үз күзләрем белән күрү күңелемдә йөрткән бер хыялым иде. Фәрит абый бу эшне тиз тотты, мине Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ренат Закиров белән таныштырды. Ренат әфәнде дә бу фикерне уңай кабул итеп, Төмәнгә бару өчен кирәкле шартлар тудырачагы турында белдерде. Нәтиҗәдә, 2015 елның 9–13 ноябрендә Төмәнгә китәргә, дип карар кылынды. Шул минутларда минем телемә Төркиядә һәр кеше яратып яттан укый торган бер шигырь килде:

Orda bir dağ var, uzakta,
O dağ bizim dağımızdır.
İnmesek de, çıkmasak da
O dağ bizim dağımızdır.

«Анда, бер тау бар, еракта,
Ул тау, безнең тавыбыз.
Төшмәсәк тә, менмәсәк тә
Ул тау безнең тавыбыз».

7 ноябрь, шимбә көнне, Истамбулдан Казанга очкан самолетка менгәндә, сөйләп кенә аңлатып булмаслык хис-тойгылар эчендә идем. Иртәгесе көнне Фәрит абый белән сәяхәтебезнең нечкәлекләрен сөйләштек. 9 ноябрь, дүшәмбе көнне, Казанның Северный вокзалыннан сәгать иртәнге сигездә кузгалачак поездга утырып, Төмәнгә юл тоттык.

Очсыз-кырыйсыз Россия киңлекләре буенча, бигрәк тә кышның салкын сулышы килеп торганда, поезд белән сәяхәт итү аеруча рәхәт икән. Моңа кадәр Төркиядә дә поездга утырганым булмаганлыктан, бу минем өчен бигрәк тә гаҗәеп тоелды. Купеларда икесе аста, икесе өстә урнашкан урыннар бар. Һәр юлчыга караватъ, одеял, чиста урын-җир әйберләре бирелә икән. Янда гына ресторан вагоны булуы да бер рәхәтлек өсти. Юлыбызны, Фәрит абый белән бергә әңгәмә корып, юлга дип алган тәм-томнарыбызны ашый-ашый, чәебезне эчә-эчә дәвам иттек. Казанда иртәнге сәгать сигездә башланган юлыбыз Әгерҗе, Екатеринбург, Красноуфимск кебек берничә шәһәрне үтеп, иртәнге сәгать дүрт тулып егерме ике минутта (Төмән сәгате белән алты тулып егерме ике минут) Төмәндә тәмамланды.

Поездан төшкәндә, һава бик суык иде. Безне дүрт көн буе сәяхәт иттерәчәк шофёрыбыз, себер татары – Газинур Сәетовның җылы каршылавы, бу суык һаваны бераз җылытып җибәргәндәй булды. Кечкенә булуына карамастан, җылы һәм тыныч кына бер кунакханәгә урнаштык. Икеөч сәгать ял иткәннән соң, иртәнге ашны ашар өчен кунакханәбезгә якын булган Төмән татар мәдәни үзәгенә киттек. Үзәктә безне бик җылы каршы алдылар. Анда Вәлимә Ташкалова һәм Бибинур Сабирова исемле бик матур ике ханым белән таныштым. Вәлимә ханым татар культура үзәгендә җитәкче булып эшләүче

бер сылу себер ханымы иде. Ул Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, үзе дә себер татарларыннан булган фольклорчы галимә, мәрхүмә Флора Урманчега бик охшаган иде. Флора ханым белән без, Измир шәһәрендә үткәрелгән бер халыкара симпозиумда танышкан идек. Вәлимә һәм Бибинур ханымнар икесе дә Флора ханым белән якын дуслар булганнар икән. Бибинур ханым күп еллар укытучы, аннан соң Төмән өлкәсенең Укытучылар белемен күтәрү институтында татар теле укытучыларының җитәкчесе булып эшләгән. Бүгенге көндә лаеклы ялда булуына карамастан, мәдәни чараларның даими катнашучысы, үзе оештырган «Ак калфак» исемле интернет-журналның редактор вазифаларын башкара. Һәр икесе дә, дүрт көн буе, яныбыздан аерылмыйча, һәр җирдә безнең ярдәмчеләребез булдылар.

Төмәндәге программабыз иртән үк башланып китте. Беренче булып, безне Төмән өлкәсе хакимиятенең Милли эшләр комитетының рәисе Евгений Михайлович Воробьёв кабул итте. Ул, бу вазифасына кадәр, Тобол шәһәренең мэры булып эшләгән икән. Без аңа Себер татарлары турындагы китапларыбызны бүләк иттек. Миңа аның Себер татарларына кагылышлы проблемалар белән якыннан таныш булуы, шуларга карата уңай фикердә булуы ошады. Ул Казанда себер татарларының антологиясе төзелә башлауны бик шатланып кабул итте. Милли эшләр комитетыннан соң, без Төмән татарларының атналык «Яңарыш» газетасына юнәлдек. Газетаның мөхәррире Алсу Сәгыйтова җитәкчелегендәге иҗат коллективы безне себер татарларының милли ризыкларыннан гына әзерләнгән мул табын белән каршы алды. «Яңарыш» газетасы 1990 елдан бирле чыгып килә икән. Гүзәл татар ашларыннан авыз итеп, себер күлләренең иң зур байлыкларыннан саналган табан балыгын бик яратып ашадым. Миңа ул гомеремдә ашаган балыкларның барысыннан да тәмлерәк тоелды. Бәхетемә, без булган себер авылларының һәркайсында мул табыннарның иң дәрәҗәле урынында бу балык куелды.

Өйләдән соң шәһәрнең бизәге булып саналган тарихи матур таш бинага урнашкан, концерт салоны, музее, тел укыту дәресханәләре булган Төмән татар мәдәният үзәгендә, Төмән җәмәгатьчелеге алдында «Сибирия татар төрекчәсе» һәм «Сибирские татары: из сокровищницы духовной культуры. Антология сибирских татар», «В.В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен, живуших в Южной Сибири и Джунгарской степи, часть 4. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» дигән китапларыбызны таныту башланды. Бу үзәкнең матди чыгымнарының бер өлешен өлкәнең атаклы эшмәкәре Ринат Насыйров каплый икән. Төмән өлкәсендә, 2010 нчы ел күрсәткечләренә караганда, 3395755 кеше яшәгән. Халык санының 73,3%ын (2352063) руслар, 239995 кешелек төркемне барлыкка китергән татарлар исә 7,5% ын алып тора.

Китапларыбыз белән таныштыру концерт салонында узды. Мин «Себер татарчасы» исемле хезмәтем белән таныштырдым, ә филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыпов «В.В. Радлов, Образцы народной литературы тюркских племен, живших в Южной Сибири и Джунгарской степи, часть 4. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар» исемле хезмәте белән «Сибирские татары. Из сокровищницы духовной культуры» исемле хезмәтләре турында сөйләде. Бу очрашуга махсус чакырылган галимнәр, татар җәмәгатьчелеге, күпсанлы мәдәният һәм мәгариф эшлеклеләре катнашты. Китап авторларының чыгышыннан соң, танытуда катнашучылар үзләрен кызыксындырган мәсьәләләре буенча сораулар бирделәр, кайбер проблемалар хакында безнең фикерләребезне белергә теләделәр. Соңыннан Төмән өлкәсенең танылган җырчылары Мөнирә Хөснетдинова, Луиза Сөрмәтова, Айсылу Йонысова һ.б. үзешчән артистлар катнашында бик матур концерт булды. Алар себер татарларының күз явын алырлык милли киемнәрендә чыгыш ясадылар. Күңелле һәм файдалы, бик җылы шартларда үткән концерттан соң, эчкерсез әңгәмәләр күңелемә хуш килде. Миңа төрекчә: «Иржан әфәнде, хуш килдегез!» – дип бер чибәр ханым сәлам бирде. Зөлфия Булдык исемле бу ханым безнең киленебез булып чыкты. Ире Карс шәһәреннән, ике балалары бар икән. Аларның матур гаилә коруларына мин бик сөендем.

Мин, Фәрит абый һәм Бибинур апа белән бергә мәрхүм фольклорчы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Флора Урманченың апасы Роза Ниязованың өендә кунак булдык. Роза ханым һәм оныгы Гүзәл безне зур бер кунакчыллык һәм ачык йөз белән каршыладылар. Алар пәрәмәч, кош теле, бавырсак, төрле бәлешләр һәм табан балыгыннан торган бик мул табын корганнар иде. Гомеремдә беренче тапкыр себер татарлары белән якыннан танышуыма чиксез шатлану һәм дулкынлану хисләрен кичердем.

Бу шатлык һәм дулкынлану хисләре чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә дә дәвам итте. Төмән районының Янбай, Түбән Тәүде районының Янтык һәм Саз (Тарман), ә икенче көнне Ялутор районының Аслана һәм Яңа Атъял авылларында булдык. Һәр авылда да күңелләребездә гомерлеккә истә кала торган үзенчәлекле каршы алулар, җирле артистларның чыгышлары хәзерләнгән иде. Мәдәни үзәктә яки мәктәпләрдә авыл халкы милли киемнәрен киеп, гармуннар уйнап, татар җырлары һәм халык уеннары белән каршы алдылар. Алыштыргысыз табан балыгы, тәм-томнарга мул табыннардан соң, безнең өчен хәзерләнгән тамашаларны карап, халыкның мәдәни сәләтенә хәйраннар булып утырдык. Төрки халыкларга гына хас булган киң күңелле авыл кешеләре тормыш-яшәешләре, өй-куралары, горурлыклары саналган мәчетләре белән дә таныштырырга

онытмадылар. Авыллар берберләреннән үзләренә генә хас булган матурлыклары белән аерылып торалар. Совет чорында мәчетләр я ябылган, я җимерелгән, яисә башка максатларда кулланыла башлаган. Милли һәм дини тормыш бары тик 1990 нчы еллардан соң гына җанлана башлаган. Нигъмәтуллаһ хаҗи Кармышаков тарафыннан Янбай авылында 1884 елда төзелгән мәчет Төмәндәге иң иске мәчетләрнең берсе санала. Ул күпләрнең игътибарын үзенә генә хас сәнгати бизәлеше белән җәлеп итә. Миңа да Янбай авылындагы тарихи мәчеттә ике рәкәгать шөкер намазы уку насыйп булды.

Мин Аслана һәм Яңа Атъял кебек кайбер авылларны электән үк ишетеп белә идем. «Себер татарчасы» исемле китабымда бу авыллардан җыелган текстлар да урын алып тора. Аслана авылында китабымны таныткында, бу авылдагы кешеләрдән тупланган материаллар да булганын сөйләдем, аларның исемнәрен атап чыктым. Текстларның язып алыну тарихы 1990 нчы елларга карый. Авторларның күбесенә бу вакытларда 70 яшь тирәсе булгандыр. Бүген аларның күбесе гүр иясе. Китабымда Фәүзия Бакиева исемле бер ханымнан язып алынган текст та бар иде. Ул вакытта Фәүзия ханым 54 яшендә булган. Ул да хәләл җефете белән безнең белән очрашуга килгән иде. Аңа хәзер 75 яшь икән. Аның исемен әйтүгә, залдагы бөтен кеше кул чабып, бер авыздан: «Менә гуй, каршыңда утырады гуй!» – диделәр. Мин бу очракка бик сөендем. Үзеннән язып алынган җырларны укып күрсәттем:

Алма бөртеккәе төшкән,
Минем яулыкларыма.
Синең сагынуларың җитми,
Минем сагынуларыма.
...
Сандугацым әйтеп сайра,
Песнең тыуганнар кайта.
Сантугац итем, ай, илемтә,
Сайрый торган итем җиремтә.
Сандугац телен белмәсәм тә.
Сайрый торган итем илемтә.
...
Утырдым көймәнең түренә,
Каратым суларның төбенә.
Сыу төпләрентә ич кара юк,
Аллам язган эшкә чара юк.

Бу җырларны укыганнан соң, Фәүзия ханым белән аның тормыш иптәшенең күңелләре нечкәреп, күзләреннән яшьләр килде: Төркиядән берсе китап язачак һәм ул китапта сезне дә телгә алачак, дип кем уйлаган инде... Бу алар өчен, әлбәттә, сөйләп бетергесез бер шатлык булды. Мин аларның икесенең арасына утырып фотога төштем. Фәүзия апа махсус минем өчен бер-ике куплетлык бер матур җыр җырлап күрсәтте, аны да камерама төшереп алдым.

Ике көн дәвамында Янбай, Янтык, Саз (Тарман), Аслана һәм Яңа Атъял авылларында гадәттән тыш мизгелләр кичердек. Дөньяның шундый ерак почмагында яшәгән, моңа кадәр миңа билгеле булмаган милләтем өчен мин тагын бер тапкыр горурлык хисләре кичердем, мине төрек булараk яратканы өчен һәм бу бөек милләтнең бер күзәнәген тәшкил итүемә Аллаһыма меңнәрчә шөкер иттем.

Дүрт көн буена дәвам иткән сәфәребез ахырына якынлашты. Барлык көннәребез авылларда үткәнлектән, Төмән шәһәрен күрү форсатыбыз булмаган иде. Шофёрыбыз Газинур абый безне берике сәгать эчендә Төмән шәһәре белән таныштырып чыгарга булды. Төмән шәһәрендәге тарихи урыннарга һәм шәһәр үзәгенә алып барды. Боз белән каплана башлаган Тура елгасын, Кызлар монастырен, Ир-атлар монастырен, иске чиркәүләрне күрү һәм рәсемгә төшерү мөмкинлеге булды. Аннан соң борынгы дип саналган «Сабыр» мәчетен зыярәт итеп, мәчетнең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт белән аралаштым. Мәчет 2003 елда торгызылган, кечкенә генә булса да, бик уңай һәм бик матур.

Казанга кайту вакыты да якынлашты. Газинур абый безне поезд станциясенә китерде. Әйберләребезне купега урнаштырдык. Карасак, перронда кулларына күчтәнәчләрен тотып Вәлимә һәм Бибинур апалар басып торалар. Безгә юлда ашарга дип, үз куллары белән татар ашлары пешереп китергәннәр. Бу яхшы күңелле кешеләрдән аерылу авыр булса да, хушлашу сәгатебез җиткән иде инде...

Поездыбыз Казанга таба хәрәкәт иткәндә, телемдә татар җырлары, йөрәгемдә ул кешеләрне ярату, акылымда еллар буе уйлап йөргән, хыялымда һәм хәтеремдә җуелмаячак гүзәл хатирәләр бураны иде. Шагыйребезнең тагын шушы юллары искә төште:

Orda bir yol var, uzakta,
O yol bizim yolumuzdur.
Dönmesek de, varmasak da
O yol bizim yolumuzdur.

Анда бер юл бар, еракта,
Ул юл, безнең юлыбыз.
Кайтмасак та, бармасак та
Ул юл, безнең юлыбыз.

Әй, газиз кавемдәшләрем, сезне гомерем буе күңел түрендә саклаячакмын, сезне беркайчан да онытмаячакмын. Ятатуыгызны һәм җылылыгыгызны һәрвакытта да йөрәгемдә йөртәчәкмен. Бу турыдагы изге төшенчәләрне миңа тагын бер кат хәтерләтүегез һәм зиһенемә сеңдерүегез өчен рәхмәт сезгә!

***Алкая Иржан,***
*филология фәннәре докторы,*
*Фырат университеты профессоры, Төркия, Элязыг*
*E-mail: ealkaya16@gmail.com*